# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 3 августында
кабул ителде

**1 статья**

Кеше һәм гражданның хокукларын һәм иреген яклау, дини экстремизмны кисәтү, конфессия эчендәге һәм конфессияара татулыкны ныгытуга ярдәм итү максатларында "Вөждан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында" 1999 елның 14 июлендәге 2279 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (II өлеш); 2001, № 12; 2004, № 2 (I өлеш); 2008, № 6; 2010, № 3; 2011, № 6 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбулада:
а) түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:
"кеше һәм гражданның хокукларын һәм ирекләрен яклау максатларында,";
б) дүртенче – алтынчы абзацларны тиешенчә бишенче – җиденче абзацлар дип санарга;

2) 11 статьяда:
а) 1 пунктта "граждан" сүзен "Россия Федерациясе гражданы" сүзләренә алмаштырырга;
б) 2 пунктта "дини оешмаларның үз билгеләүләре" сүзләреннән соң ", әгәр мондый билгеләүләр законга каршы килмәсә," сүзләрен өстәргә;

3) 15 статьяның 5 пунктында "мәгълүм үрнәктәге" сүзләрен "федераль башкарма хакимиятнең вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнгән үрнәктәге" сүзләренә алмаштырырга;

4) 17 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3, 4 пунктлар өстәргә:

"3. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән дини оешмалар руханилар вазыйфаларына кандидатларга таләпләр, шул исәптән Россия Федерациясе территориясендә урнашкан, шулай ук чит илләр территориясендә урнашкан, дипломнары билгеләнгән тәртиптә танылган мәгариф учреждениеләрендә алынган дини белем булу, шулай ук руханилар вазыйфаларын биләүгә бәйле чикләүләр урнаштыралар.

Әлеге пунктта күрсәтелгән таләпләр дини оешманың вәкаләтле органы тарафыннан билгеләнә.

4. Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән дини оешмалар дини оешманың уставында күрсәтелгән дин тәгълиматының кануный бердәмлеген тәэмин итү тәртибен билгелиләр.";

5) 19 статьяда:

а) 4 пунктта "медицина" сүзен "дәвалау-профилактика һәм хастаханә" сүзләренә алмаштырырга;

б) 5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Башка очракларда гавами гыйбадәт кылулар, башка дини йолалар һәм тантаналар митинглар, урам йөрешләре һәм демонстрацияләр үткәрү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.";

6) 27 статьяда:

а) 1 пунктта "төзергә хокуклы" сүзләрен "төзиләр" сүзенә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле 5, 6 пунктлар өстәргә:

"5. Дини оешмаларда эшләүче гражданнар үз мәнфәгатьләрен яклау өчен һөнәр берлекләре төзергә, аларга керергә, һөнәр берлеге эшчәнлеге белән шөгыльләнергә һәм һөнәр берлегеннән чыгарга хокуклы.

6. Дини оешмаларда хезмәткә кагылышлы хокук мөнәсәбәтләре, дини берләшмәләр турында законнарда билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып, хезмәт законнары белән җайга салына.".

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2012 елның 4 августы
№ 64-ТРЗ